| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**__10.03.2020__** **г. Казань** **№ ____429____**

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларына консультациягә һәм дәвалауга җибәргәндә чыгымнарны компенсацияләү тәртибе турында

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне тәэмин итү максатларында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларына консультациягә һәм дәвалауга җибәргәндә чыгымнарны компенсацияләү тәртибе турында нигезләмәне расларга.
2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Икътисадый анализ һәм фаразлау идарәсе башлыгы Г.М.Хәбибуллинага Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарга Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларында консультацияне һәм дәвалауны оештыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан ел саен финанс чараларны бүлеп бирүне алдан исәпкә алырга.
3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык идарәсе башлыгы – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш бухгалтеры Т.А. Фетисовага:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар, шул исәптән юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәре (иганәләре), исәбеннән Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче гражданнарга Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларында дәвалауга (консультациягә) бирелгән счетларны түләүне һәм компенсацион түләүләрне билгеләнгән тәртиптә үз вакытында тәэмин итәргә;

акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр М.Н.Садыйков

10.03.2020 № 429
ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы тарафыннан расланган

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларына консультациягә һәм дәвалауга җибәргәндә чыгымнарны компенсацияләү тәртибе турында нигезләмә

1.1. Гражданнарга югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтү, шул исәптән федераль дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә, бүлеп бирелгән квоталар кысаларында медицина ярдәмен күрсәтү тәртипләренә туры китереп, клиник рекомендацияләр нигезендә һәм медицина ярдәме стандартларын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

1.2. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар, шул исәптән юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәре (иганәләре), исәбеннән медицина ярдәме түбәндәге очракларда күрсәтелә:

- Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмасында дәвалауны таләп итә торган авыруның нозологик формасының Россия Федерациясе гражданнарына күрсәтелә торган югары технологияле медицина ярдәменең һәм федераль дәүләт сәламәтлек саклау учрежденияләрендә күрсәтелә торган махсуслаштырылган медицина ярдәменең төрләре исемлегенә туры килмәве;
- Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданинын (алга таба – гражданин) Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларына дәвалауга бүлеп бирелгән квоталардан тыш җибәрү;
- Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен квоталар булмаганда, Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларына дәвалауга гражданинны җибәрү;
- медицина күрсәтүләре булганда һәм Татарстан Республикасы медицина оешмаларында, Татарстан Республикасында яшәүчеләр өчен бүлеп бирелгән квоталар кысаларында югары технологияле медицина ярдәмен һәм махсуслаштырылган медицина ярдәмен күрсәтүче федераль дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендә консультация һәм/яки тикшерү уздыру мөмкинлеге булмаганда консультация һәм/яки тикшерү уздыру зарурлыгы.

1.3. Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларында консультацияләр һәм дәвалау өчен түләү медицина оешмасы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы арасында төзелгән килешү, күрсәтелгән хезмәтләр турында акт һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар, шул исәптән юридик һәм физик затларның ирекле кертемнәре (иганәләре), исәбеннән түләү өчен исәп-хисап счеты нигезендә Татарстан Республикасы

Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле акчалар кергән очракта гамәлгә ашырыла.

1.4. Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларына дәвалауга һәм/яки консультациягә киткәндә гражданнарның һәм аларны озатып йөрүче затларның туклану һәм яшәү чыгымнарын каплау гражданнарның шәхси акчалары исәбеннән башкарыла һәм компенсацияләнми.

Дүрт яшьтән өлкәнрәк баланы озатып йөрүче ата-ананың берсенә, гаиләнең башка әгъзасына яки бүтән законлы вәкилгә стационар шартларда медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмасында булган өчен түләргә кирәк булган очракта, стационар дәвалауның бөтен чорында гадәти палаталарда булу бәясен компенсацияләү баланы карау (медицина күрсәткечләре булганда) кирәклеге турында белешмә, бала карау буенча стационарда булу өчен түләү фактын раслаучы касса һәм товар чеклары (яисә билгеләнгән үрнәктәге катгый хисаптагы квитанцияләр) күрсәтелгән очракта башкарыла. Уңайлыклары югары булган палаталарда тору өчен түләү гражданнарның шәхси акчалары хисабынан башкарыла һәм компенсацияләнми.

1.5 Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларына консультациягә һәм дәвалауга баручы эшләүче гражданнар кулларында табиблар комиссиясе карары буенча билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән һәм мәҗбүри медицина иминияте полисы теркәлгән урыны буенча медицина оешмасы тарафыннан бирелгән хезмәткә яраксызлык кәгазе (чыгу хокукы белән) булырга тиеш.

1.6. Социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклы гражданинга, федераль сәламәтлек саклау учреждениялерендә дәвалануга барганда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан №2 талон бирелә.

1.7. Дәвалау урынына бушлай бару һәм кайту өчен юл документларын алу хокукын бирә торган махсус талоннар яки шәхси юлламалар белән тәэмин ителү өчен гражданин №2 талонны Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча территориаль бүлекчәсенә күрсәтә.

Социаль хезмәтләр җыелмасы рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен алуга хокуклы гражданинга №2 талонны алу өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына: федераль дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесеннән чакыру яисә өземтә күчермәсен, Татарстан Республикасыннан читтә дәвалану кирәклеге турында (әгәр авыру беренче тапкыр Татарстан Республикасыннан читкә дәвалануга чыга икән) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш штаттан тыш белгеченең яисә республика дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесенең табиблар комиссиясе бәяләмәсенең төп нөсхәсен; Россия Федерациясе гражданины паспортын (14 яшькә кадәрге балалар өчен – туу турында таныклык); мәҗбүри медицина иминияте полисын; шәхси (персональләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы һәм шәхси счетның иминият номеры турында мәгълүматы булган теркәлгән затка бирелгән документны (СНИЛС), шул исәптән электрон формада; озата баручы затның Россия Федерациясе гражданины паспортын тапшырырга кирәк.

1.8. Гражданинның социаль хезмәтләр җыелмасыннан баш тартуы очрагында, йөрү билетлары шәхси акчага алына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан компенсацияләнми.

1.9. Дәвалануга балигъ булмаган барса, юл билеты бәясе баланы озата баручы өлкән кешегә дә компенсацияләнә.

1.10. 18 яшьтән өлкәнрәк, инвалид булмаган гражданинны озата баручы затка юл билетлары бәясен компенсацияләү Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмаларында дәвалануга барганда озата бару ихтыяҗын раслый торган медицина оешмасының табиблар комиссиясенең бәяләмәсе (белешмәсе) күрсәтелгән очракта башкарыла. Гражданинның I яки II дәрәҗә инвалидлыгы булган очракта да табиблар комиссиясе бәяләмәсен (белешмәсен) күрсәтү кирәк.

1.11. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы юлламасы буенча дәвалануга киткән гражданнарга бару бәясен компенсацияләү шәһәрара транспортның түбәндәге төрләренә башкарыла:

тимер юл транспорты (уңайлыклары югары булган вагоннардан тыш барлык категориядәге поездлар һәм вагоннар);

өченче категориядәге су транспорты;

гомуми файдаланудагы автомобиль транспорты;

авиация транспорты (эконом класс), тимер юл элемтәсе булмаган очракта, ашыгыч рәвештә хастаханәгә салу кирәк булганда яки авыруны башка төр транспорт белән күчерү мөмкин булмаганда.

1.12 Юл билетлары бәясен компенсацияләү өчен түбәндәге документларның төп нөсхәләре тапшырылырга тиеш: йөрү өчен компенсация алу өчен гариза, юл билетлары (Татарстан Республикасыннан дәвалану урынына баруга һәм кире кайтуга), Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан медицина оешмасыннан өземтә күчермәсе.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән документларны стационардан чыгару вакытыннан алып 15 эш көне дәвамында  Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык идарәсенә 420111, Казан шәһ., Островский ур., 11/6 адресы буенча җибәрергә кирәк.

Документлар почта аша кыйммәтле хат белән җибәрелә яисә гражданин, гражданинны озата баручы зат яисә законлы вәкил тарафыннан тапшырыла.

Юл билетлары бәясен компенсацияләү Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле акчалар кергәннән соң башкарыла.

1.13 Медицина хезмәтләре өчен күчерелгән акчаларның куллану дөреслеген чагыштыру Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык идарәсе тарафыннан тәэмин ителә.